| МИНИСТЕРСТВО ПО ДЕЛАМ ГРАЖДАНСКОЙ ОБОРОНЫ И ЧРЕЗВЫЧАЙНЫМ СИТУАЦИЯМ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ГРАЖДАННАР ОБОРОНАСЫ ЭШЛӘРЕ ҺӘМ ГАДӘТТӘН ТЫШ ХӘЛЛӘР МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** г. Казань **БОЕРЫК**

25.02.2016 № 84

**Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре белән чит ил дәүләт, халыкара оешмалар, сәяси партияләр, башка иҗтимагый берләшмәләр һәм дини берләшмәләрнең мактаулы һәм махсус атауларын, бүләкләрен кабул итү тәртибе турында Кагыйдәнамәне раслау турында**

“Русия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәте турында” 2004 ел 27 нче июль № 79-ФЗ Федераль закон, “Русия Федерациясенең аерым дәүләт вазифаларында, федераль дәүләт хезмәтенең аерым вазифаларында булган шәхесләр белән чит ил дәүләт, халыкара оешмалар, сәяси партияләр, башка иҗтимагый берләшмәләр һәм башка оешмаларның мактаулы һәм махсус атауларын, бүләкләрен һәм башка орденнар-медальләрен кабул итү тәртибе турында Кагыйдәнамәне раслау турында” 2015 ел 10 нчы октябрь № 506 Русия Федерациясе Президенты Указы һәм Татарстан Республикасы Президенты аша билгеләп куела һәм азат ителә торган Татарстан Республикасы дәүләт вазифаларында булган шәхесләр белән чит ил дәүләт, халыкара оешмалар, сәяси партияләр, башка иҗтимагый берләшмәләр һәм башка оешмаларның мактаулы һәм махсус атауларын, бүләкләрен һәм башка орденнар-медальләрен кабул итү тәртибе турында Кагыйдәнамәне раслау турында” 2016 ел 12 нче гыйнвар № УП-5 Татарстан Республикасы Президенты Указына туры китереп, Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре белән чит ил дәүләт, халыкара оешмалар, сәяси партияләр, башка иҗтимагый берләшмәләр һәм башка оешмаларның мактаулы һәм махсус атауларын, бүләкләрен һәм башка орденнар-медальләрен кабул итүне алдан күрсәтә торган Русия Федерациясе закон нормаларын тормышка ашыруны тәэмин итү максаты белән б о е р ы к  б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре белән чит ил дәүләт, халыкара оешмалар, сәяси партияләр, башка иҗтимагый берләшмәләр һәм дини берләшмәләрнең мактаулы һәм махсус атауларын, бүләкләрен кабул итү тәртибе турында Кагыйдәнамәне расларга.

2. Биредәге боерыкны үтәү контролен министр урынбасары Н.В. Суржкога йөкләргә.

Министр Р.Җ. Хәбибуллин

2016 ел __________ № ___
Татарстан Республикасы ГТХМ
боерыгы белән расланган

**Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре белән чит ил дәүләт, халыкара оешмалар, сәяси партияләр, башка иҗтимагый берләшмәләр һәм дини берләшмәләрнең мактаулы һәм махсус атауларын, бүләкләрен кабул итү тәртибе турында Кагыйдәнамә**

1. Биредәге Кагыйдәнамә Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре (алга таба – гражданлык хезмәткәре) белән (әгәр дә гражданлык хезмәткәренең вазифа бурычларына аталган оешмалар һәм берләшмәләр белән үзара эш итүе керсә) чит ил дәүләт, халыкара оешмалар, сәяси партияләр, башка иҗтимагый берләшмәләр һәм дини берләшмәләрнең мактаулы һәм махсус атауларын (фәнниләрдән башка), бүләкләрен (алга таба – атаулар, бүләкләр) кабул итү тәртибе билгеләп куела.

2. Атаулар, бүләкләр алган вакытта гражданлык хезмәткәре Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрының (алга таба – министр) рөхсәтен алырга тиеш.

3. Атау, бүләк алган яисә чит ил дәүләт, халыкара оешмалар, сәяси партияләр, башка иҗтимагый берләшмәләр, дини берләшмәләр белән аларны булачакта алу турында белдерелгән гражданлык хезмәткәре өч эш көне эчендә кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлегенә министр исеменә чит ил дәүләт, халыкара оешма, сәяси партия, башка иҗтимагый берләшмә, дини берләшмәнең мактаулы яисә махсус атавын, бүләген кабул итү рөхсәте турында биредәге Кагыйдәнамәгә туры китереп кушымта № 1 формасы буенча төзелгән үтенеч (алга таба – үтенеч) китерә. Үтенечне карап чыгу вакыты 10 эш көне тәшкил итә.

4. Атау, бүләктән баш тарткан гражданлык хезмәткәре өч эш көне эчендә кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлегенә министр исеменә чит ил дәүләт, халыкара оешма, сәяси партия, башка иҗтимагый берләшмә, дини берләшмәнең мактаулы яисә махсус атавын, бүләген алудан баш тарту турында биредәге Кагыйдәнамәгә туры китереп кушымта № 2 формасы буенча төзелгән белдерү (алга таба – белдерү) китерә.

5. Үтенечне карап чыгу нәтиҗәләре буенча министр карары кабул ителгәнче атауны, бүләкне алган гражданлык хезмәткәре атауның документ оригиналларын, бүләкне һәм аның документ оригиналларын аларны алган көннән башлап өч эш көне эчендә кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлегенә җаваплы саклауга тапшыра. Шул ук вакытта биредәге Кагыйдәнамәгә туры китереп кушымта № 2 формасы буенча кабул итү-тапшыру акты төзелә.

6. Гражданлык хезмәткәре хезмәт командировкасы вакытында атау, бүләк алган яисә алардан баш тарткан булса, үтенеч яисә белдерүне китерү вакыты гражданлык хезмәткәре хезмәт командировкасыннан кайту көненнән санала.

7. Әгәр гражданлык хезмәткәре аннан тормаган сәбәп буенча үтенеч яисә белдерүне китерә алмаса, атауның документ оригиналларын, бүләкне һәм аның

документ оригиналларын Кагыйдәнамәнең 3 – 5 пунктларында язылган вакыт эчендә тапшыра алмаса, ул мондый сәбәпне юк иткән көннән соң алдагы эш көннән соңрак түгел үтенеч яисә белдерүне китерә, атауның документ оригиналларын, бүләкне һәм аның документ оригиналларын тапшыра.

8. Үтенечне (белдерүне) теркәү кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге белән килү көнендә биредәге Кагыйдәнамәгә туры китереп кушымта № 4 формасы буенча төзелгән теркәү журналында башкарыла. Кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге теркәлгән үтенечне (белдерүне) ике эш көне эчендә министрга карап чыгуга җибәрә.

9. Кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге ике эш көне эчендә үтенечне карап чыгу нәтиҗәләре буенча министр белән кабул ителгән карар турында гражданлык хезмәткәренә хәбәр итә, һәм аңа имзалау белән кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлегенең мөһере белән расланган министр резолюциясе белән үтенеч (белдерү) копиясен бирә.

10. Әгәр биредәге Кагыйдәнамәнең 5 нче пунктында язылган гражданлык хезмәткәренең үтенече министр белән канәгатьләндерелгән булса, кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге 10 эш көне эчендә гражданлык хезмәткәренә атауның документ оригиналларын, бүләкне һәм аның документ оригиналларын тапшыра. Шул ук вакытта биредәге Кагыйдәнамәгә туры китереп кушымта № 3 формасы буенча кабул итү-тапшыру акты төзелә.

11. Әгәр министр биредәге Кагыйдәнамәнең 5 нче пунктында язылган гражданлык хезмәткәренең үтенечен канәгатьләндермәсә, кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге 10 эш көне эчендә атауның документ оригиналларын, бүләкне һәм аның документ оригиналларын туры килә торган чит ил дәүләт, халыкара оешма, сәяси партия, башка иҗтимагый берләшмә һәм дини берләшмәнең органнарына җибәрә.

Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре белән чит ил дәүләт, халыкара оешмалар, сәяси партияләр, башка иҗтимагый берләшмәләр һәм дини берләшмәләрнең мактаулы һәм махсус атауларын, бүләкләрен кабул итү тәртибе турында Кагыйдәнамәгә
Кушымта № 1

Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министры

______________________________

______________________________
(утырган вазифа, Ф.И.О.)

______________________________

______________________________

## Чит ил дәүләт, халыкара оешма, сәяси партия, башка иҗтимагый берләшмә, дини берләшмәнең мактаулы яисә махсус атавын, бүләген кабул итү турында үтенеч

Миңа ______________________________________________________________
(мактаулы яисә махсус атау, бүләкнең документларын бирү датасы һәм урыны)

__________________________________________________________________
(нинди хезмәт өчен һәм кем белән бирелгән, нинди хезмәт өчен һәм кем белән бүләкләнгән)

__________________________________________________________________
(мактаулы яисә махсус

____________________________________________ кабул итергә рөхсәт бирергә үтенәм.
атауның, бүләкнең исеме)

Мактаулы яисә махсус атау документлары, бүләк һәм аның документлары,
(кирәклесен ассызыкларга) _____________________________________________

__________________________________________________________________
(мактаулы яисә махсус атау, бүләкнең исеме)

__________________________________________________________________
(мактаулы яисә махсус атау, бүләкнең документ исемнәре)

__________________________________________________________________

20__ ел “___”__________ № _______________ кабул итү-тапшыру акты буенча Татарстан Республикасы ГТХМ кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлегенә тапшырылганнар.

20__ ел “__”__________ ___________________ ___________________________
(имза) (имзаны ачыклау)

Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре белән чит ил дәүләт, халыкара оешмалар, сәяси партияләр, башка иҗтимагый берләшмәләр һәм дини берләшмәләрнең мактаулы һәм махсус атауларын, бүләкләрен кабул итү тәртибе турында Кагыйдәнамәгә
Кушымта № 2

Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министры

______________________________

______________________________
(утырган вазифа, Ф.И.О.)
______________________________

______________________________

## Чит ил дәүләт, халыкара оешма, сәяси партия, башка иҗтимагый берләшмә, дини берләшмәнең мактаулы яисә махсус атавын, бүләген алудан баш тарту турында белдерү

______________________________________________________________________________
(нинди хезмәт өчен һәм кем белән бирелгән, нинди хезмәт өчен һәм кем белән бүләкләнгән)

______________________________________________________________________________
(мактаулы яисә махсус атау, бүләкнең исеме)

______________________________________________________________________________

___________________________________________________ алудан минем белән баш тарту карары кабул ителгәне турында белдерәм.

20__ ел “___”__________    ___________________    ___________________________
(имза)    (имзаны ачыклау)

Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы
эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр
министрлыгында Татарстан Республикасы
дәүләт гражданлык хезмәткәрләре белән чит ил
дәүләт, халыкара оешмалар, сәяси партияләр,
башка иҗтимагый берләшмәләр һәм дини
берләшмәләрнең мактаулы һәм махсус
атауларын, бүләкләрен кабул итү тәртибе
турында Кагыйдәнамәгә
Кушымта № 3

Кабул итү-тапшыру акты

20__ ел “__”__________ № ___________

Без, аста кул куйганнар, ________________________________________________
(вазифа, Ф.И.О.)

___________________________________ түбәндәгеләрне тапшырган/кабул иткәне,
(кирәклесен ассызыкларга)
ә Татарстан Республикасы ГТХМ кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге

______________________________________________________________________
(вазифа, Ф.И.О.)

кабул иткән/тапшырганы турында акт төзедек:
(кирәклесен ассызыкларга)

| № т/б | Исем | Күләм (берәмлек) | Тасвир |
|---|---|---|---|
| | | | |
| | | | |

Тапшырган
_______________________
(имза, имзаны ачыклау)

Кабул иткән
_________________________
(имза, имзаны ачыклау)

Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре белән чит ил дәүләт, халыкара оешмалар, сәяси партияләр, башка иҗтимагый берләшмәләр һәм дини берләшмәләрнең мактаулы һәм махсус атауларын, бүләкләрен кабул итү тәртибе турында Кагыйдәнамәгә
Кушымта № 4

## Үтенечләрне (белдерүләрне) исәпләү
## ЖУРНАЛЫ

| № | Үтенечне (белдерүне) китергән гражданлык хезмәткәренең Ф.И.О. | Үтенечне (белдерүне) китергән гражданлык хезмәткәренең вазифасы | Үтенеч (белдерү) килгән датасы | Бүләк, атау исеме | Кабул итү-тапшыру актының реквизитлары (булса) | Үтенечне (белдерүне) кабул иткән шәхеснең имзасы, Ф.И.О. | Үтенечне (белдерүне) китергән шәхеснең имзасы, Ф.И.О. | Министр карары турында мәгълүмат |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | |
| | | | | | | | | |